Азнакай муниципаль районы
Микулино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

Микулино авылы № 20 «02» ноябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2016 елның 6 июнендәге 32 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (25.09.2017 №65, 30.01.2018 №85, 30.12.2019 №156, 22.04.2020 №164, 24.09.2021 №33, 07.04.2023 №10 карарлар редакциясендә)

«Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 24 июлендәге 345-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Микулино авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге Советының 2016 елның 6 июнендәге 32 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Микулино авыл җирлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында(25.09.2017 №65, 30.01.2018 №85, 30.12.2019 №156, 22.04.2020 №164, 24.09.2021 №33, 07.04.2023 №10 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 бүлекнең 1 пунктында:

а) алтынчы абзацта «, газ бүлү челтәрләре, газ куллану челтәрләре һәм мондый челтәрләр объектлары» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац белән тулыландырырга:

«- газ бүлү челтәрләренә, газ куллану челтәрләренә һәм мондый челтәрләр объектларына карата «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында»гы 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 30.5 статьясында каралган башка шартлар;»;

в) сигезенче, тугызынчы абзацларны тугызынчы, унынчы абзацлар дип санарга.

2. Әлеге карар 2023 елның 23 октябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында

Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис И.А.Тәкиулин